ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru


**КАРАР**
**«27» нче август 2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 397**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасындагы җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләрне гамәлдән чыгару турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Айбаш, Әлдермеш, Алан-Бәксәр, Каенлык, Олы Кавал, Олы Битаман, Бөреле, Биектау, Дачный, Дөбъяз, Иске-Казан, Казаклар, Красносельский, Коркачык, Мәмдәл, Мүлмә, Семиозерка, Алат, Суыксу, Ташлы-Кавал, Усад, Чернышевка, Чыпчык, Шәпше һәм Ямаширмә авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау буенча вәкаләтләрен үтәүне туктатырга.

2. Биектау муниципаль районы башкарма комитеты һәм Айбаш, Әлдермеш, Алан-Бәксәр, Каенлык, Олы Кавал, Олы Битаман, Бөреле, Биектау, Дачный, Дөбъяз, Иске-Казан, Казаклар, Красносельский, Коркачык, Мәмдәл, Мүлмә, Семиозерка, Алат, Суыксу, Ташлы-Кавал, Усад, Чернышевка, Чыпчык, Шәпше һәм Ямаширмә авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасындагы җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау буенча вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләрне гамәлдән чыгарырга һәм аларны күрсәтелгән муниципалитетларның авыл җирлекләре Советларына карау өчен җибәрергә.

3. Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 30 маендагы 300 нче

номерлы «Биектау муниципаль районы башкарма комитеты һәм Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында җирлекләрнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау буенча вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләрне раслау турында» карары үз көчен югалтуын таныарга.

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

6. Әлеге Карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин